РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ МАЛОБУИНКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАТАР БУАСЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

01 июнь 2022 ел № 46-1

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Татар Буасы авыл җирлегендә җирләрдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проекты хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты, Буа муниципаль районының Татар Буасы авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Татар Буасы авыл җирлеге советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Татар Буасы авыл җирлеге Советының 2013 елның 05 февралендәге 2-33 номерлы «Буа муниципаль районы Татар Буасы авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре турында» карары белән расланган Буа муниципаль районы Татар Буасы авыл җирлегеннән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре турында» карары белән расланган Буа муниципаль районы Татар Буасы авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә (27.06.2016 № 14-2, 23.09.2017 № 37-1, 12.02.2019 № 61-1, 22.06.2021 № 22-1, 01.03.2022 № 38-2, 04.05.2022 № 44-1 номерлы карарлары редакциясендә) (алга таба-Кагыйдә) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 1статья:

24 абзацны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Торак кодексының 15 статьясындагы 6 өлеше нигезендә, Россия Федерациясе Торак кодексының 36 статьясындагы 1 өлешенең 1-3 пунктларында күрсәтелгән мөлкәтне үз эченә алган ике һәм аннан күбрәк фатирдан торган бина күпфатирлы йорт дип таныла. Күпфатирлы йорт шулай ук торак булмаган биналарның һәм (яки) машина-урыннарның аерым милекчеләренә караган, мондый күп фатирлы йортның аерылгысыз өлеше булып торган урыннарын үз эченә ала.»;

2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Татар Буасы авыл җирлегендә Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эш төркеме төзергә;

- эш төркеме җитәкчесе:

Йосыпов Рәүф Фарук улы - Татар Буасы авыл җирлеге башлыгы;

- эш төркеме әгъзалары:

Замалетдинова Роза Мансур кызы - Татар Буасы авыл җирлеге секретаре;

Гыйльфанов Ринат Мансур улы-Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура бүлеге башлыгы;

Рахматов Булат Рафаэль улы-Буа муниципаль районы Советы Аппаратының юридик бүлеге башлыгы (килешү буенча).

3.Билгеләргә:

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Татар Буасы авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы карар проектына тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Татар Буасы авыл җирлеге Советына түбәндәге адрес буенча кертелә: ТР, Буа районы., Татар Буасы авылы, Яшләр ур., 33нче йорт А, язма рәвештә, карар проекты рәсми басылып чыккан көннән алып 30 көн эчендә, эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Татар Буасы авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы карар проекты буенча ачык тыңлауларда чыгыш ясау хокукы белән катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча тапшырыла: ТР, Буа районы., Татар Буасы авылы, Яшләр ур., 33нче йорт А, эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, ачык тыңлаулар үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Татар Буасы авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы карар проекты буенча Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Татар Буасы авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә ачык тыңлаулары үткәрү турында нигезләмәдә каралган тәртиптә әлеге проект буенча ачык тыңлауларны 2022 елда “27” июнь 10.00 сәгатьтә Татар Буасы авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында үткәрергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/), шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http://buinsk.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Буа муниципаль районы Татар Буасы авыл
җирлеге башлыгы, Совет рәисе Р.Ф. Йосыпов